Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Никольский авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

05 ноябрь 2019 ел N 1

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Яңа Никольский авыл җирлегенең
Салкын Алан авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Салкын Алан авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл җирлегенең Салкын Алан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 5600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Техника һәм аңа асылмалы җиһазлар сатып алу?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын Салкын Алан авыл мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Салкын Алан авылы, Болын урамы, 40 нчы йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Никольский авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Салкын Алан авылы, Болын урамы, 60 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Яңа Никольский авыл
җирлеге башлыгы Х.Х. Дәүләтгәрәев